ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 ноябрь 2021 ел № 7336

2022 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмаларын финанслау нормативларын исәпләү тәртибен раслау турында» 2020 елның 27 мартындагы 1541 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) 2022 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны;

2) 2022 елга сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга төзәтмә кертү коэффициентын 0,5 күләмендә.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны әлеге карарның 1 пунктында каралган норматив чыгымнарга туры китереп тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми

хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 15 ноябрендәге
7336 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең
сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү
мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүгә
норматив чыгымнар

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль дислокациясе | Норматив чыгымнар (елына 1 укучыга сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өчьеллык укыту срогы | дүртьеллык укыту срогы | бишьеллык укыту срогы | җидееллык укыту срогы | иртә һөнәри ориентация |
| Музыка сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 55 793 | 64 719 | 84 130 |
| Сынлы сәнгать | шәһәр җирлеге | | 30 808 | | 26 803 | 64 347 |
| Хореография сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 58 474 | 48 228 | 175 835 |
| Гомуми эстетика сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 25 592 | | |
| Фольклор сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 55 174 | 52 945 | 85 700 |
| Эстрада-джаз сәнгате | шәһәр җирлеге | 84 971 | | 81 330 | | 134 297 |
| Театр сәнгате | шәһәр җирлеге | 43 848 | | 40 718 | 40 728 | 64 463 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева